| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОКУВАКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>«ИСКЕ КУАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026елның 18 феврале № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 декабрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасының икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин ур., 36 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

Лениногорск муниипаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Н.Сушкова